СОВЕТ БОЛЬШЕЕЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ЕЛОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

**Татарстан Республикасы Олы Елово авыл җирлегенең
2020 елга һәм 2021 һәм 2022 елларның планлы чорына бюджеты турында**

**ОЛЫ ЕЛОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАРЫ**

№ 171 «17» декабрь 2019 ел

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Олы Елово авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы һәм “Олы Елово авыл җирлегендә бюджет барышы турында” Нигезләмәгә туры китереп, Олы Елово авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

**1 маддә**

1. 2020 елга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Олы Елово авыл җирлеге бюджетының (алга таба – Җирлек бюджеты) төп сыйфатларын расларга:
   1) Җирлек бюджеты керемнәренең фаразланган гомуми күләме 1 557,0 мең сум;
   2) Җирлек бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 1 557,0 мең сум;
   3) Җирлек бюджетының дефициты 0 мең сум күләмендә.

2. 2021 һәм 2022 елларга Җирлек бюджетының төп сыйфатларын расларга:
   1) 2021 елга Җирлек бюджеты керемнәренең фаразланган гомуми күләме 1 601,8 мең сум һәм 2022 елга 1 650,9 мең сум;
   2) 2021 елга Җирлек бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 1 601,8 мең сум, шул исәптән шартлы расланган чыгымнар 37,7 мең сум, 2022 елга 1 650,9 мең сум, шул исәптән шартлы расланган 77,9 мең сум күләмендә;
   3) Җирлек бюджетының дефициты 2021 елга 0 мең сум, 2022 елга 0 мең сум күләмендә.
3. 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 елларның планлы чорына Җирлек бюджеты дефицитын финанслау чыганакларын шушы Карарның 1 кушымтасына туры китереп расларга.

**2 маддә**

1. Җирлек муниципаль эчке бурычының өске чиген 2021 елның 1 гыйнварына 0 мең сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча йөкләмәләрнең өске чиген 0 мең сум күләмендә расларга.
2. 2022 елның 1 гыйнварына Җирлек муниципаль эчке бурычының өске чиген 0 мең сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча йөкләмәләрнең өске чиген 0 мең сум күләмендә расларга.
3. 2023 елның 1 гыйнварына Җирлек муниципаль эчке бурычының өске чиген 0 мең сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча йөкләмәләрнең өске чиген 0 мең сум күләмендә расларга.
4. Җирлек муниципаль бурычының чик зурлыгын:

2020 елда – 0 мең сум күләмендә;

2021 елда – 0 мең сум күләмендә;

2022 елда – 0 мең сум күләмендә расларга.

**3 маддә**

2020 елга һәм 2021 һәм 2022 елларның планлы чорына Җирлек бюджеты керемнәренең фаразланган күләмен Җирлек бюджетында шушы Карарның 2 кушымтасына яраштырып исәпләргә.

**4 маддә**

1. Җирлек бюджеты керемнәренең төп администраторлары исемлеген шушы Карарның 3 кушымтасына яраштырып исәпләргә.

2. Җирлек бюджетының дефицитын финанслау чыганакларының төп администраторлары исемлеген шушы Карарның 4 кушымтасына яраштырып расларга.

**5 маддә**

1. 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 елларның планлы чорына Җирлек бюджетының оешма эчтәлеген шушы Карарның 5 кушымтасына яраштырып расларга.

2. Җирлек бюджетының бюджет ассигналауларын бүлекләр, бүлекчәләр, максатчан маддәләр (эшчәнлекнең программалы һәм программалы булмаган юнәлешләре), 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 елларның планлы чорына бюджет чыгымнары классификациясенең чыгым төре төркемнәре буенча бүлүне шушы Карарның 6 кушымтасына яраштырып расларга.

3. Җирлек бюджетының бюджет ассигналауларын максатчан маддәләр (эшчәнлекнең программалы һәм программалы булмаган юнәлешләре), 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 елларның планлы чорына бюджет чыгымнары классификациясенең чыгым төре төркемнәре, бүлекләре, бүлекчәләре буенча бүлүне шушы Карарның 7 кушымтасына яраштырып расларга.

4. 2020 елга ачык норматив йөкләмәләрне үтәүгә бюджет ассигналауларының гомуми күләмен 0 мең сум күләмендә, 2021 елга 0 мең сум күләмендә һәм 2022 елга 0 мең сум күләмендә расларга.

**6 маддә**

Җирлек бюджетында бюджет тәэмин ителешенә дотацияне:
- 2020 елга 1 280,0 мең сум күләмендә,
- 2021 елга 1 322,5 мең сум күләмендә,
- 2022 елга 1 365,1 мең сум күләмендә исәпләргә.

**7 маддә**

Җирлек бюджетында хәрби комиссариатлары булмаган урыннарда беренчел хәрби исәпне башкару буенча вәкаләтләрне тормышка ашыруга субвенцияне:
- 2020 елга 92,1 мең сум күләмендә,
- 2021 елга 92,2 мең сум күләмендә,
- 2022 елга 93,7 мең сум күләмендә исәпләргә.

**8 маддә**

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Олы Елово авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары 2020 елда һәм 2021 һәм 2022 елларның планлы чорында муниципаль хезмәткәрләр, шулай ук җирле үзидарә органнары һәм муниципаль казна учреждениеләре хезмәткәрләренең санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хаклы түгел.

**9 маддә**

Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгының Казначылык органнары Илмәт авыл җирлегенең бюджетын үтәү буенча аерым эшләрне башкаралар.

**10 маддә**

Җирлек бюджеты чараларыннан 2020 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Олы Елово авыл җирлеге исеменнән, товар китерүгә, эш башкаруга, хезмәт күрсәтүгә төзелгән муниципаль контрактларга файдаланмаган бюджет ассигналауларын әлеге контрактлар шартлары нигезендә 2019 елда түләнергә тиешле түләүнең калганы 2020 елда, Олы Елово авыл җирлеге тарафыннан тиешле карар кабул ителгән очракта, күрсәтелгән максатларга тиешле бюджет ассигалауларын арттыруга юнәлдерелә.

**11 маддә**

Шушы Карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә һәм массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми басылырга тиешле.

**Олы Елово авыл җирлеге**
**башлыгы** **А.И. Машанов**